КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 май г.Казань № 317

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 ноябрь, 646 нчы; 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан (01.15.03<*>)».

3.3 пунктның 3.3.7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә ия объектлар өчен атмосфера һавасына рөхсәт ителгән һәм вакытлыча килештерелгән зарарлы (пычратучы) матдәләр чыгаруны билгели;

төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә ия су кулланучылар өчен су объектларына пычратучы матдәләр (радиоактив матдәләрдән тыш) һәм микроорганизмнар чыгаруга рөхсәтләр бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин